**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 4 сентябре** **№ 79**

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 19 июнендәге “Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү Кагыйдәләрен яңа редакциядә раслау турында”гы 42 номерлы карарына (2017 елның 14 ноябрендәге 59 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге 70 номерлы карарлары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында**

2017 елның 29 декабрендәге 477-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында”гы Федераль законының 15 маддәсенә үзгәреш кертү турында”гы Федераль закон нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 19 июнендәге 42 номерлы карары белән (2017 елның 14 ноябрендәге 59 номерлы, 2018 елның 6 июнендәге 70 номерлы карарлары редакциясендә) расланган, “Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәреш кертергә:

Кагыйдәләрнең 85.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“85.8. туктап тору территориясенә инвалидларның тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү. Транспорт чараларының һәр туктау урынында, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, I, II төркем, шулай ук III төркем инвалидлар йөртә торган транспорт чараларын һәм шундый инвалидларны һәм (яисә) инвалид балаларны йөртүче транспорт чараларын түләүсез парковкалау өчен 10 проценттан ким булмаган (әмма

кимендә бер урын) урын бүлеп бирелә. Күрсәтелгән урыннарны парковкалау өчен башка транспорт чаралары биләргә тиеш түгел.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Иске Барыш авылы, Үзәк ур., 15;

- ТР, Кама Тамагы районы, Картапа авылы, Мәктәп ур., 10; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Барыш авыл җирлеге Башлыгы,
Татарстан РеспубликасыКама Тамагы
муниципаль районы Иске Барыш
авыл җирлеге Советы рәисе И.Р. Җиһаншин